**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы**
**Уразай авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

Уразай авылы №33 «10» август 2021ел

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Уразай авыл җирлеге Советының 2021 елның 15 февралендэге 19 нчы номерлы карары белән расланган, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Уразай авыл җирлеге территориясендә Россия Федерациясе дәүләт урман фонды җирләренә керми торган һәм физик һәм юридик затларның хосусый милкендәге җирләрдә яшел утыртмаларны кисү тәртибе турында нигезләмәгә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында

Россия Федерациясе Урман кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елныц 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Әйләнә-тирә мохитне саклау турында» 2002 елның 10 гыйнварындагы 7-ФЗ номерлы Федераль закон, Уразай авыл җирлеге территориясендә, Россия Федерациясе дәүләт урман фонды җирләренә кермәгән һәм физик һәм юридик затларныц хосусый милкендәге җирләргә кермәгән, яшел утыртмаларны рациональ файдалану, саклау һәм яцадан җитештерү максатыннан, Азнакай шәһәр прокуратурасының 2021 елның 28 июнендәге №02-08-02-2021номерлы таләбен исәпкә алып

Уразай авыл җирлеге Советы карар итте:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Уразай авыл җирлеге Советының 2021 елның 15 февралендэге 19 нчы номерлы карары белән расланган, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Уразай авыл җирлеге территориясендә Россия Федерациясе дәүләт урман фонды җирләренә керми торган һәм физик һәм юридик затларның хосусый милкендәге җирләрдә яшел утыртмаларны кисү тәртибе турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә:

1.1. 3.5 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.5. Авыл җирлеге башкарма комитеты мөрәҗәгать итүче хат-гаризасы, яшел үсентеләрне техник тикшерү акты, киселгән агач очен түләүне (түләүне) исәпләү нигезендә өч эш көне дәвамында авыл җирлеге башкарма комитеты авыл җирлеге территориясендә яшел үсентеләр кисүгә рөхсәт бирү турында күрсәтмә проектын әзерли.».

1.2. 3.11 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.11. Агач кискән өчен түләүне башкармыйча гына, агач һәм куакларны кисү авыл җирлеге башкарма комитеты тарафыннан түбәндәге очракларда рөхсәт ителә:».

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» урнаштыру юлы белән түбәндәге веб-адрес буенча игълан итәргә: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының Интернет-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында түбәндәге веб-адрес буенча урнаштырырга: http//aznakayevo.tatarstan.ru.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны торак-коммуналь хуҗалык, төзекләндерү, экология һәм җир мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Рәис: А.М.Шэрифуллина